**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

тугызынчы утырыш

# КАРАРЫ

15 нче май 2026 ел **№ 48** Теләче ав.

Теләче муниципаль районы Советының 2020 елның 1 июнендәге 232 номерлы «Теләче муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тәкъдим иткән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары хакында» Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1. Теләче муниципаль районы Советының 2020 елның 1 июнендәге 232 номерлы «Теләче муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тәкъдим иткән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» карарына (2023 елның 26 июнендәге 193 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны били торган затка, үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тәкъдим иткән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында»;

Б) преамбуладагы «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары хакында»

сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары хакында» сүзләренә алыштырырга;

В) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Кушымта итеп бирелгән Муниципаль вазыйфаны били торган затка, үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тәкъдим иткән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибен расларга.»;

2. Әлеге карар белән расланган Теләче муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тәкъдим иткән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә:

А) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны били торган затка, үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тәкъдим иткән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе»;

Б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлеше нигезендә муниципаль вазыйфаны биләүче затка үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр, шулай ук керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм әгәр бу мәгълүматларны бозу гамәлдә булмаса, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәти характердагы йөкләмәләрендә, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) җирле үзидарәнең тиешле органында вазыйфа биләүче затны вазыйфасыннан азат итү һәм аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчы тиешле җирле үзидарә органында вазыйфаларны биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3) аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчы тиешле җирле үзидарә органында вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.»;

В) 3 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен нигез булып муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында «Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлешендә каралган Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) Советка кергән гаризасы тора.»;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы А.Г. Фатхуллин